КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 декабрь г.Казань № 1233

«Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә гавами сервитут билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының V$^{7}$ бүлеге, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3$^{6}$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә, «Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте (ИНН 1655049111, ОГРН 1021602830930) мәнфәгатьләрендә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренә (алга таба – җир кишәрлекләре) карата 49 елга гавами сервитут (алга таба – гавами сервитут) билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән «Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында гавами сервитут чикләре урнашу урынының график тасвирламасын расларга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

гавами сервитут өчен түләүне исәпләү һәм кертү тәртибе Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{46}$ статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла;

җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә алардан файдалану мөмкин булмаячак яки шактый авыр булачак срогы гавами сервитут срогына туры килә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районына җибәрүне;

бу карарның күчермәләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, җир кишәрлекләренең хокук ияләренә җибәрүне.

5. «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән гавами сервитутны гамәлгә ашыру турында килешүләр төзүне;

федераль дәүләт энергетика күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары нигезендә бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән объектка карата саклау зонасы чикләрен килештерү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән электр челтәре хуҗалыгы объектына техник хезмәт күрсәтү буенча тәэмин ителеше өчен гавами сервитут билгеләнгән план (регламент) эшләрен елга бер тапкыр гамәлгә ашыруны;

җир кишәрлекләрен аларның рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне;

гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын, тәэмин ителеше өчен гавами сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясында билгеләнгән вакытларда сүтүне.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 декабрь, 1233 нче
карарына кушымта

Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында гавами сервитут урнаштырыла торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Бердәм җирдән файдаланунын кадастр номеры | Җир кишәрлегенең хокук иясе | Хокук төре | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар нигезендә җир кишәрлегенең урнашу урыны | Гавами сервитут урнаштырыла торган мәйдан, кв.метр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | 16:15:070501:61 | 16:15:000000:83 | «Восточная Земельная Компания» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте<br><br>«Восток Зернопродукт» акционерлык җәмгыяте | Милек<br><br>Аренда | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, «Экопласт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җирләрендә | 6 966 |
| 2. | 16:15:070501:68 | | | | | 1 885 |
| 3. | 16:15:070501:60 | | | | | 694 |
| 4. | 16:15:070501:59 | | | | | 31 141 |
| 5. | 16:15:070501:58 | | | | | 11 833 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | 16:15:070501:270 | 16:15:000000:307 | «Красный Восток Агро» акционерлык җәмгыяте | Өлешле милек | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Килди авыл җирлеге | 886 |
| 7. | 16:15:070501:291 | | | | | 319 |
| 8. | 16:15:070501:37 | 16:15:000000:355 | «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | Милек | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы | 6 |
| 9. | 16:15:070501:40 | | | | | 9 |
| 10. | 16:15:070501:41 | | | | | 6 |
| Барлыгы | | | | | | 53 745 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 декабрь, 1233 нче
карарына кушымта

«Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге
электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында
гавами сервитут чикләре урнашу урынының график тасвирламасы

1 бүлек

| Объект турында мәгълүматлар | | |
|---|---|---|
| Т/с | Объектның тасвирнамәләре | Тасвирнамәләрнең тасвирламасы |
| 1 | Объектның урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Килди авыл җирлеге |
| 2 | Объектның мәйданы +/- мәйданны билгеләү төгәлсезлеге зурлыгы (Р +/- Дельта Р) | 53 745 кв.м +/- 73 кв.м |
| 3 | Объектның башка тасвирнамәләре | Гавами сервитут урнаштырылган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:15:070501:61 (ЕЗ 16:15:000000:83), 16:15:070501:291 (ЕЗ 16:15:000000:307), 16:15:070501:68 (ЕЗ 16:24:000000:83), 16:15:070501:60 (ЕЗ 16:24:000000:83), 16:15:070501:59 (ЕЗ 16:24:000000:83), 16:15:070501:270 (ЕЗ 16:24:000000:307), 16:15:070501:58 (ЕЗ 16:24:000000:83), 16:15:070501:37 (ЕЗ 16:24:000000:355), 16:15:070501:40 (ЕЗ 16:24:000000:355), 16:15:070501:41 (ЕЗ 16:24:000000:355) |

2 бүлек

| Объект чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билгесенең тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чик өлешенең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билгесенең тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 өлеш | | | | | |
| 1 | 449255.05 | 1280103.57 | Аналитик | 0.1 | - |
| 2 | 449258.75 | 1280153.43 | Аналитик | 0.1 | - |
| 3 | 449004.41 | 1280172.30 | Аналитик | 0.1 | - |
| 4 | 448604.73 | 1280068.77 | Аналитик | 0.1 | - |
| 5 | 448460.35 | 1280212.16 | Аналитик | 0.1 | - |
| 6 | 448259.11 | 1280227.04 | Аналитик | 0.1 | - |
| 7 | 448255.43 | 1280177.17 | Аналитик | 0.1 | - |
| 8 | 448438.23 | 1280163.66 | Аналитик | 0.1 | - |
| 9 | 448589.70 | 1280013.22 | Аналитик | 0.1 | - |
| 10 | 449008.95 | 1280121.83 | Аналитик | 0.1 | - |
| 1 | 449255.05 | 1280103.57 | Аналитик | 0.1 | - |


3 бүлек

| Объектның үзгәртелгән (тәгаенләнгән) чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16 | | | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Гамәлдәге координатлар, м | | Үзгәртелгән (тәгаенләнгән) координатлар, м | | Характерлы ноктаның координат-ларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билгесенең тасвир-ламасы (булганда) |
| | X | Y | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| - | - | - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| - | - | - | - | - | - | - | - |

4 бүлек

«Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында гавами сервитут чикләре урнашу схемасы

Объект чикләренең күзәтү схемасы




Масштабы 1: 25 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар:


– объект чиге

– инженерлык корылмасының проекттагы урнашу урыны (110 кВ һава линиясе күчәре).

4 бүлек

### «Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында гавами сервитут чикләре урнашу схемасы

1 бит




Масштабы 1: 5 000


Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

| | |
|---|---|
| • 1 | – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе |
| (кызыл сызык) | – объект чиге |
| (кызгылт сары өзек сызык) | – инженерлык корылмасының проекттагы урнашу урыны (110 кВ һава линиясе күчәре) |
| (яшел сызык) | – кадастр кварталы чиге |
| (сары турыпочмак) | – җир кишәрлеге чиге |
| 16:15:070601 | – кадастр кварталы номеры |
| 16:15:070501:41 | – җир кишәрлегенең кадастр номеры. |

4 бүлек

«Макыл – Мәйдан 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында гавами сервитут чикләре урнашу схемасы

2 нче бит




Масштабы 1: 5 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

• 1 – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе

– объект чиге

– инженерлык корылмасының проекттагы урнашу урыны (110 кВ һава линиясе күчәре)

– җир кишәрлеге чиге

16:15:070501:41 – җир кишәрлегенең кадастр номеры.